СОВЕТ
ТУКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТУКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
СОВЕТЫ
ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

пр. М. Джалиля, 46, г. Набережные Челны, 423800

М. Җәлил пр., 46, Яр Чаллы шәһәре, 423800

Телефон/факс (8552) 70-37-82, tukay@tatar.ru

23.04.2021 № 9/17

На №__________от____________

# КАРАР

**Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» вн/1 номерлы карарына үзгәрешләр кертү турында**

Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару эшен оптимальләштерү һәм Татарстан Республикасы Президентының 2006 елның 23 октябрендәге Указы белән расланган Татарстан Республикасы Дәүләт органнарында дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын һәм Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләре реестрын алып бару тәртибе турында нигезләмәгә үзгәрешләр кертү нигезендә муниципаль берәмлек Советы

**КАРАР БИРДЕ:**

1. Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Советының 2019 елның 22 февралендәге «Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәне раслау хакында» вн/1 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районында муниципаль хезмәт турында нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 34 статьяның 34.4 пунктын яңа редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы органнарында, шул исәптән электрон чыганакларда, муниципаль хезмәткәрләрнең персональ мәгълүматлары нигезендә төзелә торган муниципаль хезмәткәрләр реестрлары алып барыла, реестрны алып бару бары тик «Татарстан Республикасының дәүләт граждан хезмәте һәм Татарстан Республикасында муниципаль хезмәт кадрлар составының бердәм мәгълүмат системасы» Татарстан Республикасы дәүләт мәгълүмат системасында гына гамәлгә ашырыла.

2. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында (http://tukay.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

3. Әлеге карар үтәлешен контрольдә тотуны законлылык, милли мәсьәләләр һәм халык куркынычсызлыгы буенча даими комиссиягә йөкләргә.

Муниципаль берәмлек Башлыгы,
Совет Рәисе Ф.М. Камаев